# КАРАР

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге составына керүче Иске Ибрай авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 25 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә "2021 елда һәр балигъ булган һәм Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге Иске Ибрай авылы территориясендә теркәлгән кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә (1 төркем инвалид, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш) һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән алдагы эшләрне башкару буенча:

1) җирлекнең торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;:

- Иске Ибрай авылы урамнарына вак таш сатып алу;

- Иске Ибрай авылында Тукай, Комсомол, Мәдәният, Октябрь, урамнары буенча юл нигезен грунт белән төзү һәм тигезләү.

- авыл юлларын кышын карап тоту (килешү буенча түләү).

2) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә, халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру,

- суүткәргеч ремонтлау өчен насос һәм комплектлар сатып алу ;

ӘЙЕ ЮК ТЫЕЛЫП КАЛАМ

" белән килешәсезме?" мәсьәләсе буенча 2020 елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде,

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1306 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 764 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
- "әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 719 кеше тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
- «тыелып калам» позициясе өчен җыенда катнашучы 45 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1) җирлекнең торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;:

- Иске Ибрай авылы урамнарына вак таш сатып алу;

- Иске Ибрай авылында Тукай, Комсомол, Мәдәният, Октябрь, урамнары буенча юл нигезен грунт белән төзү һәм тигезләү.

- авыл юлларын кышын карап тоту (килешү буенча түләү).

2) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә, халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру,

- сууткәргеч ремонтлау өчен насос һәм комплектлар сатып алу ;

3. Әлеге карарны Иске Ибрай авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы М.Г.Минигулов